Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Ивановка авыл җирлеге
Михайловка авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 21 ноябрь № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Михайловка авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән,1 төркем инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

I. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Үзәк урамы буенча (25нче йорттан һәйкәлгә кадәр) юлларга вак таш җәю;
- Михайловка авылында (Үзәк ур., Югары ур.) юлларны кардан чистарту

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Ивановка авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ивановка авыл җирлеге башлыгы А.П.Бодряева